**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЗУР КЛЮЧИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«15» сентябре 2021 елның** **№46**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы
Зур Ключи авыл җирлеге Советының
«Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы «Зур Ключи авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге территориясендә җир
салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында»
2019 елның 1 ноябрендәге 208 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президенты Р. Н. Миңнехановның 2017 елның 13 июнендәге вн-5507-МР күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Салым кодексына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зур Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зур Ключи авыл җирлеге Советы карар:

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зур Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» Зур Ключи авыл җирлеге Советының 2019 елның 1 ноябрендәге 208 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.8 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында»2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтле махсус оешмалар милкендә булган җир кишәрлекләренә карата 1.8) 0,001%»

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Яшел Үзән муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), Яшел Үзән муниципаль районы, Зур Ключи авылы, Волостнов урамы, 16а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Зур Ключи авылы, Волостнов урамы, 21 йорт (кибет бинасы) адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.

**Зур Ключи авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С. Е. Комягин**